**Сагитова Гүзәл**

**Казан – татарның, Татарстанның башкаласы.** Әлеге фикер күбрәк рәсми чыганакларда яши, ә чынлыкта бу дөреслеккә туры киләме? Шуңа охшаш тәнкыйди сораулар Казанга карата еш яңгырый иде**. 2021 елны туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы** дип игълан иткәч тә, без әлеге калыплышкан фикерне үзгәртүконкрет адымнар ясарга булдык. Татар телен үстерүгә, аны популярлаштыруга багышланган 15кә якын өр-яңа проектка нигез салынды.

**Беренче булып, без төп игътибарны мәгарифкә юнәлттек.**

1) Татар телендә тәрбия, белем биргән бакча-мәктәпләргә **бәйсез мониторинг ясалды.** Әлеге анализны Татарстанның Фәннәр академиясе һәм Казан федераль университетының бәйсез экспертлары башкарып чыкты.

**Мониторинг түбәндәге юнәлешләрдә эшләргә кирәклеген күрсәтте:**

- милли (татар) балалар бакчалары һәм мәктәпләре имиджын үстерү өчен махсус стратегия язу;
- **татар мәктәпләре һәм балалар бакчаларына ребрендинг ясау;**
- заманча реалияләрне һәм яшь буынның кызыксынуларын истә тотып, милли тәрбия системасын модернизацияләү;
- **белем бирү учреждениеләренең статусын күтәрү һәм аларның биналарын камилләштерү;**

- балалар һәм укытучылар арасында аралашуны татар телендә алып бару;
- **укучылар өчен аңлаешлы, кызыклы күнегүләр, текстлар белән баетылган җиңел дәреслекләр әзерләү;**
- яшь буынгататар телен өйрәнүгә мотивация булдыру

**Безнең бурыч – басым ясау түгел, ә мотивацияләргә, мәҗбүр итәргә түгел, ә яңа мөмкинлекләр ачарга.** Шул максаттан без татар теле укытучылары өчен семинарлар циклын башлап җибәрдек. Мәктәпләрдә татар теле дәресләрен кызыклырак һәм нәтиҗәлерәк итү өчен укытучыларның квалификациясен арттыру – бу очрашуларның төп миссиясе. Спикерлар укытучыларны инглиз, япон телләрен укыту буенча дөньядагы иң алдынгы методикалар һәм практикалар белән таныштырды. **2022 елда да семинарларны дәвам итәбез.** Аларның беренчесе февраль аенда татар балалар бакчаларында эшләүче **500гә якын тәрбияче, методист** өчен узды. Быелгы семинарлар Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан хупланылды. Эшне Сезнең ярдәмдә дәвам итәбез, Марат Готович, зур рәхмәт!

Шулай ук **Туган телләр елында Казанда берничә уку-укыту программасы** тормышка ашырылды: хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләүчеләргә татар телен өйрәтү буенча интенсивлар. Аның программасы өч юнәлештән гыйбарәт иде: **кунакханә бизнесы өлкәсе, җәмәгать туклануы һәм сату-алу өлкәсендә эшләүчеләр өчен.** Башкарма комитет хезмәткәрләре өчен аерым интенсив үтте.

Муниципаль хезмәткәрләр үз чиратында тел белү дәрәҗәсенә карап ике төркемгә бүленеп белем алдылар. Без бу практиканы дәвам итәргә ниятлибез: быел интенсивны дәүләт транспорты хезмәткәрләре өчен дә оештыру уе да бар.

Узган елның апрель аенда, Тукайның тууына 135 ел тулу уңаеннан **татар телендә өр-яңавидеоролик күрсәтелә** башлады. Сөйләм телен үстерүгә багышланган **20 ролик Казан метросының телепанельләрендә һәм социаль челтәрләрдә трансляцияләнде**. Әлеге видеоязмаларны Марат Готыф улы быел да дәвам итү кирәклеген белдерде, комисия ярдәме белән хәзерге вакытта яңа темаларга видеороликлар эшләнелә. Әгәр былтыр әлеге видеороликларда татар теленең нигезләре өйрәтелсә, быел аларда киңрәк төшенчәләр тәкъдим ителә. Шулай ук аларга юмористик элементлар да өстәлә. Әйдәгез, аның берсен карап узыйк. (Видео)

Былтыр Казанның парк һәм скверларында июньнән алып сентябрьгә кадәр иҗат һәм спорт дәресләре буенча мастер-класслар уздырылды. Кабан күле яр буенда, «Ак чәчәкләр» һәм Фучик урамындагы бульварларда, Горький исемендәге һәм «Черек күл» ял паркларында йога, стретчинг, сулыш алу күнекмәләре, «Чабата» биюе, импровизацияләнгән джем һәм халык биюләре буенча төрле шәхесләр татар телендә 14 мастер-класс үткәрде.

2022 елның февраль аеннан башлап, «**Хәрәкәттә – бәрәкәт»** проекты Казанның 20 мәктәбенә күчте. Аның белән беррәттән шәһәрнең 20 мәктәбендә **«Сөйлә»** проекты гамәлгә ашырыла. **«Хәрәкәттә-бәрәкәт»** проектында яшь буын татар биюе

хәрәкәтләрен өйрәнә. «Сөйлә» проектында укучылар нәфис сүз жанрын камилләштерә, әдәби әсәрләрне югары профессиональ дәрәҗәдә сөйләргә өйрәнә. Әлеге проектларны иҗади тамаша белән йомгакларга телибез.

Искәртеп узыйк, бу ике проект та Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән үткәрелә.

26 июньдә Казан Сабантуе көннендә «**Урам» экстрим-паркында «Яңа Сабантуй» яшьләр фестивале** узды. Элеккеге заманнарда яшьләр җыела торган кичке Сабантуй гореф-гадәтен без шул рәвешле, 21нче гасырда яңарттык. Чара көндезге Сабантуйдан соң яшьләрне экстремаль төрдәге ярышлар, заманча музыка һәм биюләр, үзара аралашу белән берләштерде.

Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында татар әдәбиятына да игътибар зур булды.Шушы елның тагын бер мөһим проекты – **«Саумы, Казан!»** хикәяләр конкурсы. Әлеге бәйгегә 120кеше катнашты, шуларның 6сы җиңүче итеп сайлап алынды. Иң яхшы, дип табылган татар һәм рус телендәге әсәрләрне без китап итеп бастырып чыгардык. (китапны күрсәтү)

Республика көнендә **«Казан тавышлары» перформансы** да күпләрнең исендә калды. Казанның нәкъ уртасында, мэрия балконнарыннан Роберт Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт шигырьләре яңгырап торды. 60 еллар шигърияте арт-визуализация ягъни меппинг ярдәмендә яңача ачылды.

Әлеге ел татар шигъриятенең иң мөһим чорларын үз эченә алган **«Сөйли торган материя» әдәби-музыкаль** кичәсе белән тәмамланды. Шулай ук әлеге чарада елга йомгаклар ясалып, безнең эшләгән активистларны бүләкләү тантанасы узды.

Депутатлар корпусы да Туган телләр елыннан читтә калмады. Казан шәһәре Думасы депутаты Рөстәм Рамазанов белән татар телен өйрәнүгә һәм татар мәдәниятен үстерүгә багышланган **«Үз телем» проектлар** конкурсын тәкъдим иттек. Бәйгедә татар телен нәтиҗәле итеп өйрәнү һәм популярлаштыру идеясе булган һәркем катнаша алды. **Бүләкләү фонды – бер миллион сумны тәшкил итте**. Әлеге проектны Рөстәм Рамазанов финанслады. **146 идеядән 26сы икенче** этапка узды. Алар арасында татар телендә уен стримнары, дубляж мәктәбе, балалар өчен журналлар, Казан турында комикслар, уеннар белән кушымталар бар иде. Нәтиҗәдә, **5 җиңүчегә** проектларын гамәлгә ашыру өчен грантлар тапшырылды. Җиңүчеләрнең берсе – Регина Гаязова **“Татарча комикслар” китабын 12 мартта** Милли китапханәдә тәкъдир итте, калганнары ел дәвамында тормышка ашырылачак.

Узган елның 20 сентябрьдән Казан метросында «Туган телләр поезды» йөри башлады. Ул канатлы сүзләр, гыйбарәләр, юмор, популяр фразалар бизәлгән алты вагоннан тора. 6 вагонның 3 се татарлар, Татарстанга багышланган иде, 1 вагон тулысынча татар телендә. Мондый транспорт концепциясе белән Татарстан районнары администрацияләре, шулай ук күрше Чувашия республикасы да кызыксынды".

Быел исә комиссия белән бергә әлеге концепцияне автобусларга да күчерү нияте бар. Шулай ук автобусларда татар һәм рус телләрендә топонимика, шәхесләргә бәйле аудиогид та эшли башланды.

Идел буе халыкларын берләштергән беренче "Итил" арт фестивале, Булу күргәзмәсен дә татарлыкка да, татарга да урын зур булды, ләкин аларга аерым тукталып тормыйм.

**Май чүлмәге тышыннан билгеле,** диләр. Казан Башкарма комитетының рәсми сайтлары ике телдә алып барыла иде. Ләкин халык белән туры элемтә – ул **социаль челтәрләр**. Без шәһәрнең инстаграм-аккаунтын татар телендә эшли башладык, аның @kzn_official_tat дигән Тукай телендә сөйли торган бите барлыкка килде. Моңа өстәп, шулай ук **"Иске шәһәр" префектурасының** инстаграмы да туган телебездә алып барыла башлады.

Социаль челтәрләр татарча мөхит тудыруның бер ысулы да. Шулай ук Казан урамнары атамалары, муниципаль һәм хосусый оешмаларда, иҗтимагый биналарда элмә такталардагы икетеллелек **Казанны татарчалаштыра торган зур күрсәткеч**. Бу уңайдан үзгәрешләр күзгә күренерлек булмагач, Казан урамнарына үзебез мониторинг үткәрергә булдык.Эшне Казанның төп урамы - Бауман урамыннан башларга булдык. Элмә такталарны тикшерү максатыннан өч рейд ясалды, **соңгы рейд Башкарма комитеты җитәкчесе Рөстәм Гафаров** белән берлектә оештырылды. Эшмәкәрләргә хатлар язылды, алар белән очрашулар булды. Ләкин

без шуны аңладык: **законга үзгәрешләр кертмичә, үзебезгә генә бу эшне башкарып чыгу мөмкин түгел.**

Марат Готович, без Сезгә **элмә такталарда татар теле рус теле белән бертигез дәрәҗәдә кулланылсын өчен** Татарстан Республикасы Дәүләт Советына **«Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында»**Законга элмә такталарына кагылышлы үзгәрешләр кертү үтенече белән Дәүләт Советына мөрәҗәгать белән чыгуыгызны сорап хат юллаган идек. Бу җаваплы, зур эшне башкарып чыгарга язсын!

Искәртеп узыйк, Казан мэриясе проектлары Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы белән генә туктап калмады, алар быел да дәвам итә. Быел иң зур яңалыгыбыз: **Казан мэриясе каршында “Апуш” балалар татар театр** студиясен ачтык. **26-27нче февральдәге кастингта** Казан шәһәре, Лаеш, Балтач, Арча районнарыннан 9-15 яшьлек 100гә якын укучы катнашты. Нәтиҗәдә, студиягә 32 укучы сайлап алынды. Алар атнага өч тапкыр «Сәйдәш» мәдәният үзәгенә дәресләргә йөри.

“Апуш”ның төп максаты – укучыларда татар теленә кызыксыну уяту, яшьләргә иҗади сәләтләрен ачарга ярдәм итү, милли мәдәниятне үстерү. Укучылар татарча спектакльләр әзерләячәк, төрле шәхесләр белән мастер-классларда катнашачак, сәхнә теле, сәхнә хәрәкәте, актерлык осталыгы, вокал буенча дәресләр алачак. Иң мөһиме – студиягә йөрү бушлай. Беренче спектакльне тәкъдим итү быелның 1нче июненә планлаштырыла.

«Сәйдәш» мәдәният үзәгендә башланган студия уңай нәтиҗәләр күрсәтсә, 2023 елда студияне Ленин исемендәге мәдәният сараенда, 2024 елда Сәид-Галиев исемендәге Мәдәният йортында (Дәрвишләр бистәсе) һәм Тимерьюлчылар мәдәният йортында да (Юдино бистәсе) да ачарга телибез.

**Теле барның – юлы бар**, ди халык мәкале. Димәк, **киләчәге бар**. Һәрберебез үзебезчә тырышабыз, үз даирәсендә, үз темпында. Башлангычлар, чыннан да, күп. Әлеге проектлар дәвамлы булсын, ел саен тормышка ашырылсын иде! Чөнки бу очракта гына без системалы эш алып барылу турында сөйли алабыз. Казан - милли сорауларны хәл итүдә дә алгы рәттә булуын телибез.

Татарча, заманча, халыкның күпчелеген җәлеп итә торган проектларны миллионнан артык халкы булган шәһәрдә тормышка ашырып буламы? Моннан берничә ел элек Казан татарларның башкаласы булуы күбрәк сүздә генә кала дигән тәнкыйть сүзләрен еш ишетергә туры килә идеКазан башкарма комитеты бу юнәлештә үзгәрешләр, яңалыкка омтылыш булуын күрсәтте һәм күбрәк эшләү өчен мөмкинлекләр ачты.

Нәкъ менә былтыр без, Казан мэриясе командасы, татарча проектларны, чыннан да, дөньяви трендларга туры килерлек итеп оештырып була икәнлегенә инандык.

Ел дәвамында без җәмәгать эшлеклеләре һәм экспертлар белән очрашулар һәм консультацияләр уздырдык. Аларның сораулары һәм идеяләре безне шәһәр халкы белән бергә тормышка ашырылган күп кенә проектларга этәргеч булды. 2021 елда мэрия татар теленә кагылышлы нинди эшләр башкарырга тиеш, кайсы юнәлешкә аеруча игътибар кирәклеген нәкъ менә тел активистлары белән сөйләшкән идек. Ул түгәрәк өстәлдән үзебез өчен бик күп идеяләр, илһам алдык. Һәм күп эшләрне дә алар белән бергә кулга-кул тотынышып башкарып чыктык.

Балалар бакчалары, мәктәпләр буенча мөрәҗәгатьләр күп булу, заманча фикерли торган, яңа методик ысуллар белән эшләүче кадрларга кытлык булу әлеге белем учреждениеләрендә мониторинг уздыруга ихтыяҗ тудырды.

**Шулай ук, киләчәктә рус телле балалар бакчалары һәм мәктәпләре белән бергә полилингваль белем бирү яисә татар телендәге учреждениеләрне дә үстерү мөһим. Марат Готович җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе соравы буенча Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов прогимназияләрне үстерүгә акча бүлеп бирде. Шул сәбәпле, 18нче прогимназияне төзекләндерү күздә тотыла, тагын 3 прогимназия өчен җир әзерлибез.**

**шартлар тудыру, мавыктыргыч дәресләр ясау, укытуда яңа алымнар куллану, барлык туган тел укытучыларның квалификациясен күтәрү, балаларда телне өйрәнүгә кызыксыну уяту.**

**Әмма ТЕЛ бакча, мәктәп кысаларында гына калырга тиеш түгел. Укытучылар һәм тәрбиячеләрнең телгә өйрәтү тырышлыклары бушка китмәсен өчен, без шәһәрдә тел мохитен булдырырга тиешбез.**

**Марат Готович, әлеге чараларга югары бәя биреп, хуплавыгыз һәм 2022 елда бу проектны Казанның татар мәктәпләрендә дәвам итәргә ярдәм итүегез өчен Сезгә зур рәхмәт!**

**Комиссия белән планнарыбыз әле моның белән генә тәмамланмый. Марат Готович безне дә үз канатыгызга алган өчен зур рәхмәт Сезгә!**

**Австрия композиторы Густав Малер болай ди: «Традиция — это передача огня, а не поклонение пеплу». («Гореф-гадәт – улкөлгәтабынутүгел, ә буыннан-буынга ялкынтапшыру»). Моны истә тотып,**

**Белгәнебезчә, «Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы үтәлешен Васил Гаптелгаяз улы Шәйхразиев җитәкчелегендәге Татарстан Республикасында телләр турындагы законны гамәлгә ашыру Советы контрольдә тота.**

**Аерым алганда, «Белдерү, афиша, элмә такта, режим такталары һәм башка күрсәтмә мәгълүмат текстлары Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерелә. Җитештерелә торган продукциянең ярлыклары, инструкцияләре, этикеткалары рус телендә, шулай ук җитештерүче теләге буенча, татар телендә һәм (яки) Россия Федерациясе халыкларының туган телләрендә рәсмиләштерелә», дип тиешле үзгәрешләр кертү, аннан соң**

**муниципаль хокукый актларга үзгәрешләр кертү таләп ителә. Бу эшнең уңай якка хәл ителәсенә өметләнәбез.**

**Без аңлыйбыз, киләчәктә ата-аналарга балаларын татар төркемнәрендә тәрбияләүнең өстенлеген аңлату эшләрен оештыру да мөһим. Балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә өстәмә татар телле түгәрәкләр оештыру. Робототехника, татарча математика, анимация ясау кебек кызыклы түгәрәкләр булса, ата-аналарны мондый мәктәпләргә җәлеп итү күпкә җиңелрәк булыр иде.**

**Сүз бары тик татар телле бакчалар һәм мәктәпләр турында гына бармый. Әлеге вакытта татар мәктәпләре җитми икән, рус телендә тәрбия һәм белем биргән бакча һәм мәктәпләрдә татар сыйныфлары, төркемнәрен яисә кызыклы түгәрәкләр булдыру – кулыбыздан килә торган эш.**